КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 май г.Казань № 373

Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәмнең кайбер чараларын күрсәтү үзенчәлекләре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, махсус хәрби операциядә катнашучы затларга, хәрби хезмәткәрләр арасыннан затларга, ирекле формированиедә булу турында контракт төзегән затларга, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә хезмәт итүче затларга (алга таба – махсус хәрби операциядә катнашучылар), шулай ук аларның ата-аналарына, хатыннарына, балигъ булмаган балаларына түбәндәге социаль ярдәм чараларын күрсәткәндә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычларның булуы исәпкә алынмый дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарының 2 пунктында билгеләнгән пенсионерларга транспортта юл йөрү өчен айлык акчалата түләү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карарының 1 пунктында билгеләнгән даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга айлык өстәмә акчалата түләү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бала туганда авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карарының 1 пунктында билгеләнгән бала туганда авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган түләү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карарының 1 пунктында билгеләнгән 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында» 2019 ел, 3 декабрь, 1095 нче карарының 1 пунктында билгеләнгән «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган дару чараларын һәм даруханә ассортиментының башка товарларын сатып алуга түләүләр.

2. Әлеге карарның 1 пунктында, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 – 7 статьяларында, 8 статьясындагы 7 һәм 8 пунктларында, $8^1$ һәм $8^3$ статьяларында күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатларында махсус хәрби операциядә катнашу фактын раслый торган документларны әлеге хезмәтләр файдалану өчен мөрәҗәгать итүче гражданнар «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлегенә (алга таба – Үзәк бүлеге) мөстәкыйль рәвештә тапшыралар.

Үзәк бүлеге махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзаларына кертеп карауның хокукый нигезләре раслана торган белешмәләрне ведомствоара рәсми сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып электрон рәвештә ала.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин